| МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

______23.01.2017_______ г. Казань №_______89_______

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актларын һәм норматив хокукый актларның проектларын коррупциягә каршы экспертизаны уздыру Тәртибен раслау турында

2009 елның 17 июленнән № 172-ФЗ «Норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» Федераль законына, 2010 елның 26 февраленнән №96 «Норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карарына, 2009 елның 24 декабреннән № 883 «Аерым норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарына туры китереп боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру Тәртибен расларга.
2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы идарәләренең һәм бүлекләренең башлыкларына тәэмин итәргә:

коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен эшкәртелә торган норматив хокукый актларын һәм норматив хокукый актларның проектларын Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының юридик бүлегенә үз вакытында тапшыруны;

хәзерге боерык белән раслаган тәртиптә юридик бүлеккә бу проектларны җибәрү көненә ярашлы эш көне дәвамында бәйсез коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен «Интернет» информацион-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының рәсми сайтында норматив хокукый актларның проектларын урнаштыруны.

3. Боерыкның үтәлүен тикшерүне үз өстемдә калдырам.

Министр А.Ю. Вафин

2017 елның ______ № __
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгының
боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру Тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актларның проектларына (түбәндә – актлар, актларның проектлары), аларда коррупцияне тудыручы факторларны ачыклау, аларны шуннан соң бетерү максатында, коррупциягә каршы экспертиза уздыру процедурасын хәзерге Тәртип билгели.

1.2.Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры юридик бүлегенең хезмәткәрләре арасыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау Министрлыгында коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен җаваплы шәхесне (түбәндә – урындагы кешене) билгели.

Күрсәтелгән урындагы кеше шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында (түбәндә – Министрлык) «Коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларын һәм норматив хокукый актларның проектларын исәпләү журналын» (түбәндә – Журнал ) алып бару өчен җаваплы була. Журналда коррупциягә каршы экспертизага кергән актлар һәм актларның проектлары турында, экспертизаның уздыру датасы һәм нәтиҗәләре турында мәгълүматлар күрсәтелә.(Хәзерге Тәртипкә № 1Кушымта).

## II. Министрлык актларына, актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру

2.1. Коррупциягә каршы экпертиза уздыру өчен актлар, актларның проектлары, аның инициативасы буенча шушы акт кабул ителгән (акт проектын эшләү өчен җаваплы) структур бүлекчәнең җитәкчесе белән юридик бүлеккә җибәреләләр.

Актлар шулай ук Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры белән экспертиза уздыру өчен җибәрелергә мөмкин.

2.2. Акт (акт проекты) коррупциягә каршы экспертизага керү вакытында урындагы кеше кирәкле мәгълүматларны Исәпләү журналына язып куя һәм актка (акт проектына) коррупциягә каршы экспертиза уздыра.

2.3. «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» Федераль законына, 2009 елның 24 декабреннән № 883 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары белән расланган Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру Тәртибенә туры китереп, Россия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләнгән методикасы буенча коррупциягә каршы экспертиза урындагы кеше белән уздырыла.

2.4. Коррупциягә каршы экспертизаны башкару процессында кирәклек очрагында урындагы кеше коррупциягә каршы экспертизада кызыксынган структур бүлекчәләрдән һәм урындагы кешеләрдән өстәмә материалларны яисә мәгълүмат сорарга һәм алырга хаклы.

Сораган материаллар һәм мәгълүмат сорауны алган мизгелдән өч көннән артык булмаган срокта урындагы кешегә тапшырылырга тиеш.

2.5. Актларга (актлар проектларына) коррупциягә каршы экспертиза уздыру срогы иң күбе ун көн тәшкил итә.

2.6. Урындагы кеше уздырган экспертизаның йомгаклары буенча нәтиҗә төзә (хәзерге Тәртипкә №2 Кушымта).

2.7. Нәтиҗәдә түбәндәге мәгълүматлар күрсәтеләләр:

- экспертизага тапшырылган акт реквизитлары (акт проектының исеме);
- экспертиза уздыру өчен нигез;
- тишерелгән актта, акт проектында коррупцияне тудыручы факторларның булуы яки булмавы;
- актның, акт проектының коррупцияне тудыручы факторлар булган конкрет нигезләмәләр;
- хокукый нормаларының формулировкаларын үзгәртү яисә коррупция тудыруны чыгару өчен аерым нормаларны бетерү буенча тәкъдимнәр.

## III. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсен башкару

3.1. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча төзелгән, хәзерләнгән һәм урындагы кеше белән имза куелган нәтиҗә шушы актка (акт проектына) коррупциягә каршы экспертиза җибәргән шәхескә, һәм коррупция тудыручы факторлар булуы очрагында – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрына җибәрелә.

3.2. Әгәр актта коррупция тудыручы факторлар ачыкланды, аның инициативасы буенча акт кабул ителгән структур бүлекчәсе җитәкчесе, нәтиҗәне алгач, өч көн дәвамында үзгәртүләр кертү яисә коррупциягә каршы экспертизаның предметы булган актны көч югалткан дип тану турында норматив хокукый актның проектын хәзерләргә яисә акт проектына тиешле

үзгәрешләр кертергә һәм урындагы кешегә коррупциягә каршы экспертизаны уздыру өчен җибәрергә тиеш.

Кабаттан коррупциягә каршы экспертиза уздыру срогы күбесе өч көн тәшкил итә.

3.3 Әгәр коррупциягә каршы экспертизага җибәрелгән акт проектында коррупция тудыручы факторлар юк, аны эшләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе җитәкчесе Министрлыкның кызыксынган структур бүлекчәләр белән акт проектын үзара килешүне һәм проектны Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрына имза куюга юнәлтүне тәэмин итә.

## IV. Министрлык актларына һәм акт проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза

4.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары – рәсми бастырып чыгарылган актлар һәм Министрлыкның рәсми сайтында «Интернет» информацион-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырылган актларның проектлары.

4.2. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлары яки конфиденциаль характердагы мәгълүматлары булган актларга һәм акт проектларына карата уздырылмый.

4.3. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен структур бүлекчәнең акт проектын эшләп чыгару өчен җаваплы булган хезмәткәре (түбәндә – эшләүче) аны Министрлыкның рәсми сайтында «Интернет» информацион-телекоммуникацион челтәрендә юридик бүлеккә проектны юнәлдерү көненә ярашлы эш көне дәвамында урнаштыра.

4.4. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен акт проектларын урнаштыру вакытында эшләүче турында (фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын, контакт телефонын, эксперт нәтиҗәсен җибәрү өчен электрон почта адресын), коррупциягә каршы бәйсез экспертиза йомгаклары буенча нәтиҗәләрне кабул итүнең башлау һәм тәмамлау датасы турында өстәмә мәгълүматлар күрсәтергә кирәк.

4.5. Акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру эшләүче белән билгели торган срогы Министрлыкның рәсми сайтында «Интернет» информацион-телекоммуникацион челтәрендә урнаштыру көненнән башлап бишь көн тәшкил итәргә тиеш.

4.6. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза йомгаклары буенча нәтиҗә тәкъдим рәвешен йөртә һәм аның инициативасы буенча шушы акт буенча кабул ителгән (проектны эшләү өчен җаваплы) структур бүлекчәсе җитәкчесе белән аны алу көннән 15-көнлек срокта мәҗбүри каралырга тиеш.

Карау нәтиҗәләре буенча бәйсез экспертиза уздыручы юридик яки физик шәхескә дәлилләнгән җавап, нәтиҗәдә ачыкланган коррупция тудыручы факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмау очракларынан тыш, җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгының
норматив хокукый актларына һәм
норматив хокукый актларның проектларына
коррупциягә каршы экспертиза
уздыру Тәртибенә
№1 Кушымта

**Коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларын һәм норматив хокукый актларның проектларын исәпләү журналы**

| Акт/актның проекты экспертизага керү датасы | Актны/актның проектын тапшырган структур бүлекчәсе | Акт/актның проекты исеме | Нәтиҗә/ экспертизаны үздыру датасы | Урындагы кеше |
|---|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** |

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгының
норматив хокукый актларына һәм норматив
хокукый актларның проектларына коррупциягә
каршы экспертиза уздыру Тәртибенә
№2 Кушымта

**Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертизаның**
**НӘТИҖӘСЕ**

Экспертизага тапшырылган актның (акт проектының) исеме һәм резкизитлары ______________________________________________________

Коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен нигез:

Актта (акт проектында) коррупция тудыручы нормалар булуы яки булмавы:

Коррупция тудыручы нормалар булган актның (акт проектының) конкрет нигезләмәләре: ________________________________________________

Коррупция тудыруын бетерү өчен формулировкаларны үзгәртү яисә аерым нормаларны чыгару буенча тәкъдимнәр: ______________________________

(Җаваплы шәхес вазыйфасы) (имза) (Фамилия, исем, атаның исеме)